ҮЗӘКТӘ – БАЛА

Казанда яңа перинаталь үзәккә нигез ташы салынды

> 2

МАКСИМ КУЗНЕЦОВ:

«Татар телен алтынчы ел өйрәнәм»

> 3

СӘХНӘДӘН – ОСТАХАНӘГӘ

Чаллы театры артисты Илдар Гадиев агачтан үзенчәлекле җиһазлар ясый

> 4

САБАК АЛГАННАРМЫ?

«Ак барс» Гагарин Кубогы өчен көрәшне башлый

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 30 (28803) | Чәршәмбе | 2 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

АКЧАНЫҢ ТЫНГЫСЫЗ ЧАГЫ

Актуаль тема

Көн тудымы – яңа хәбәр. Атна башында Россия Үзәк банкы төп ставканы 20 процентка кадәр арттырды. Бу соңгы еллардагы рекордлы күрсәткеч дип бәяләнә. Моңа кадәр төп ставка 9,5 процент тәшкил итә иде. Үзәк банк мондый адым икътисади чикләүләр аркасында бәяләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү, халыкта булган акчаның кыйммәтен саклау өчен кирәк дип аңлатты.

Алга таба ни көтәргә? Белгечләрнең бер өше бик тиздән ипотекага бөтенләй ясин чыгарга туры килмәгәе дип фаразлый. Ай саен кредит түләп яшәүчеләрнең исә – үз кайгысы. Моңа кадәр рәсмиләштергән кредитларның да ставкасы арта күрмәгәе дип курка алар. Ник дигәндә, соңгы көннәрдә Үзәк банкның төп ставканы күтәрүе аркасында моңарчы алынган кредитларның да ставкалары артачак икән дигән имеш-мимешләр таралды.

Рәсми җавап озак көттермәде. Россия Президенты Владимир Путин моңа кадәр рәсмиләштерелгән кредит ставкаларын үзгәрешсез калдырырга кушты. Ил башлыгының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков сүзләренә караганда, бу боерык ипотека кредитларына кагыла. «Президент икътисади мәсьәләләр буенча киңәшмәдә төп ставка 20 процентка күтәрелгәнче төзелгән кредит килешүләрендәге ставкаларның барысын да саклап калырга кушты», – дип белдерде ул журналистларга. Бу хәбәрне бер-бер артлы банклар да раслады. Саклык банкы, ВТБ, Альфа-банк кебек эре банклар клиентларын беренчеләрдән булып тынычландырды. Искәртәбез: бу бары тик ипотека кредитларына гына кагыла.

Бу вакыйга кредит белән бәйләнгән кешеләрнең тагын бер мәсьәләгә күзләрен ачты. Фәлән ел элек рәсмиләштереп, айлык түләвен вакытында кертеп барган кредитыңның да көннәрдән бер көнне процентын арттырып куя алуларыннан күпләр хәбәрдар түгел булып чыкты. Юрист Роман Архипов сүзләренә караганда, мондый куркыныч үзгәрә торган ставкалы кредитларга яный. «Әмма андый ставкалы кредитлар бик аз бирелә. Бүген алар илдә рәсмиләштерелгән барлык кредитларның 3 процент чамасын гына тәшкил итә. Ипотека кредитыннан бигрәк, куллланучы кредиты төзегәндә күбрәк кулланыла. Шуңа күрә кредит рәсмиләштергәндә килешүне игътибар белән укырга кирәк. Киләчәктә кредитның ставкасын үзгәртү ихтималы анда аерым пункт итеп күрсәтелгән булырга мөмкин», – ди юрист.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Олег Коробченко фикеренчә, килеп туган вазгыятьтә паникага бирелергә кирәкми. Илнең резервлары икътисадны тотрыклы рәвештә тотарлык дәрәҗәдә дип саный ул.

– Төп ставканы 20 процентка кадәр күтәрү акча массасы белән спекуляцияләр булмасын өчен эшләнде. Мондый шартларда акчаны кулда сакламау хәерле. Доллар сатып алырга да кирәкми. Артык акчаны акцияләр яки милек сатып алуга тоту отышлырак, – дип белдерде депутат «ВТ» хәбәрчесенә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Үзәк банкның көтелмәгән хәбәреннән соң банклар барлык төр кредит һәм кертемнәргә ставкаларны арттырды. Үзгәреш җиле иң беренчеләрдән булып ВТБ банкыннан исте. Банк җитәкчелеге әле узган ялларда гына ипотека кредитларын рефинанслау өчен гаризалар кабул итүне туктату турында хәбәр иткән иде. Үзәк банк хәбәреннән соң исә бирелә ипотеканың минималь ставкасы 15,3 процентка җитте. Кертем һәм саклык счетларына акчаны исә ВТБда 18 процент ставка белән салырга мөмкин. Саклык банкында исә кертемчеләргә 16,5 процентка (ипотека ставкасы 18,6 процентка җиткән. – **Д.Г.**) кадәр ставка тәкъдим итәләр.

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов кертемчеләргә бу шартларда артык хискә бирелмәскә киңәш итә.

– Депозит ставкаларын кертем срогы беткәч кенә яңадан карарга була. Килешүне вакытыннан алда өзгән очракта кертем ставкасы 0,1 процент кына булырга мөмкин. Шуңа күрә кертемнең срогы тулганчы көтәргә, аннары инде банклар тәкъдим иткән депозит ставкасы белән яңадан килешү төзергә кирәк, – ди ул. – Бүгенге вазгыятьтә акчаны банкта саклауны дәвам итәргә кирәк. Ник дигәндә, акча алсаң да югала. Аны хәзер доллар, еврога алыштырудан мәгънә юк. Банктагы кертемнәрнең 1,4 миллион сумга кадәр өлеше иминиятләштерелгән. Банклар банкротлыкка чыккан очракта да кешегә кертемнәренең әнә шулкадәр өлеше тулысынча түләнәчәк.

Илгизәр Гайнетдинов якын арада ипотека рәсмиләштерергә җыенган кешеләргә бераз сабыр итәргә киңәш итә. Ник дигәндә, төп ставка арту белән барлык төр кредит ставкалары гына түгел, торак бәясе дә котырып үсәчәк. Ипотека ставкалары 20 процентттан да артса, ипотека программасына бөтенләй ясин чыгарга туры киләчәк дип фаразлый белгечләр. «Бәхетле йорт» милек агентлыгы башлыгы Анастасия Гыйззәтова сүзләренә караганда, торак базарында мәхшәр башланган инде. «Куркуыннан банктагы кертемнәрен, картадагы акчаларын салдырган кешеләр хәзер бу акчаларны, милек алып, саклап калырга тырыша. Булган фатирын яки йортын сатып, ипотека ярдәмендә зуррак торак алырга теләгән кешеләргә хәзер аеруча сак булырга кирәк. Ник дигәндә, банк белән эш барып чыкмаса, торыр җирсез һәм кулдагы очсызлана баручы акча белән урамда калуыгыз да бар», – дип кисәтә белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Икътисадны кайгырту

Россиядә санкцияләр шартларында икътисадның тотрыклылыгын үстерү буенча оператив штаб булдырылган. Аңа Премьер-министр Михаил Мишустин җитәкчелек итәчәк. Бу хакта Россия Хөкүмәтенең матбугат хезмәте хәбәр итә. Премьер-министр махсус киңәшмәдә билгеләп үткәнчә, АКШ һәм Европа берлеге илләре ягыннан икътисади басым көчәйгәннән-көчәя. Алар халыкның мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагылучы чикләүләр кертә.

Соңгы елларда илдә импортны алыштыру, үзебезнең товар җитештерүчеләргә ярдәм итү буенча күп кенә карарлар кабул ителгән. Аларны гамәлгә ашыру өчен 2018 елда икътисадның тотрыклылыгын үстерү буенча Хөкүмәт комиссиясе оештырылган. Менә хәзер ул оператив штаб режимына күчерелә. Аның башлыгы урынбасары итеп беренче вице-премьер Андрей Белоусов һәм Мәскәү мэры Сергей Собянин билгеләнгән.

Ишегалды яңара

«Безнең ишегалды» Президент программасы буенча республиканың 40 муниципаль берәмлегендә 1200 ишегалды төзекләндереләчәк. Быел 298 мең кешенең ишегалды яңартылачак дигән сүз бу.

2022 елда әлеге максатка 9 миллиард сум тотылачак. Акчаны бюджеттан тыш чыганаклар хисабына Президент Рөстәм Миңнеханов җибәрәчәк. Быел ишегалларын төрлечә төзекләндерү, зуррракларында спорт мәйданчыклары булдыру күздә тотыла. Әйтик, бер ишегалдында яшәүчеләр күрше ишегалдындагы мәйданчыкта спорт белән шөгыльләнә алачак. Шулай ук ишегалдыннан шәһәрнең мөһим нокталарына кадәр җәяүлеләр сукмаклары салыначак. Мәсәлән, Чаллыда 9 һәм 10 нчы комплексларны Габдулла Тукай исемендәге Яр буе һәм Кәрим Тинчурин исемендәге бульвар белән тоташтыру планлаштырыла. Менделеевскиның өченче микрорайонындагы ишегалдында велосипедчылар юлы булдырылачак. Ә инде Казанның Батыршин урамындагы 35, 37 нче йортлар ишегалларында тарихи мозаиканы яңарту һәм эт-песиләр белән йөрү өчен махсус урыннар оештыру күздә тотыла.

Бәяләрне йөгәнлиләр

Монополиягә каршы федераль хезмәт төбәкләрдәге идарәләренә халыкка иң кирәкле азык-төлек бәяләрен күзәтүне көчәйтергә кушкан. Җитештерүчедән алып, сәүдә челтәренә кадәр бәяләргә күз-колак булып торырга тиеш. Аерым алганда, товар хакын нигезсез арттыру, үз ягыңны гына кайгыртып файдалану, бәяләрне үзара килешеп арттыру очраклары ачыкланачак.

Исегезгә төшерәбез: АКШ, Европа берлеге илләре һәм кайбер башка илләр Россия компанияләренә каршы санкцияләр кертте.

Вазгыять

Бөтен өмет – мартка

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк иҗтимагый бүлеге сәламәтлек темасына бәйле сораулар буенча халыкны кабул итү атнасын башлап җибәрде. Бу җәһәттән социаль челтәрләрдә белгечләр катнашында «туры эфир» да каралган. Шушы көннәрдә коронавируска бәйле вазгыять турында сөйләштеләр. Төп сорауларга җавапларны тәкъдим итәбез.

1. «Омикрон»мы, «дельта»мы?

Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина сүзләренчә, республикада коронавирус белән авыручыларның 90 процентында – «омикрон» штаммы. Калганы – «дельта» штаммы белән авыручылар.

Сүз уңаеннан, 1 мартка булган мәгълүмат буенча, Татарстанда 2029 кешедә коронавирус ачыкланган, шуларның 307се – балалар. Чир йоктыручыларның 173ен хастаханәгә салганнар.

2. Балаларга нинди ярдәм күрсәтелә?

Коронавирус йоктырган балаларга медицина ярдәме Татарстанның вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитальләрендә күрсәтелә, алар – җидәү. Республика балалар клиник хастаханәсе баш табибы Айрат Зыятдинов сүзләренчә, яшүсмерләргә вакцина ясату эше дәвам итә.

Гомумән, Татарстанда COVID-19га каршы 2463291 кеше вакцина ясаткан. Прививканың икенчесен 1925700 кеше алган. Кабат вакцинация узучылар – 246251 кеше.

3. Чир кайчан бетәр?

Татарстанда коронавирус белән чирләүчеләр кими бара. Любовь Авдонина әйтүенчә, бу елның гыйнварыннан авыручылар саны кискен арта башлаган иде. Көненә өч, дүрт меңләп авыру теркәлгән чорны да уздык.

– Сигезенче атнадан чирләүчеләрнең, узган атна белән чагыштырганда, 30 процентка азаюын күрәбез. Коронавируска каршы барлык таләпләрне төгәл үтәгән очракта, эпидемиологик вазгыятьнең тотрыклануы нәтиҗәсендә мартта гамәлдәге чикләүләрне бетерү турында да уйларга мөмкин булачак, – диде Любовь Авдонина.

4. Чирдән соң тормыш турында.

Татарстанның баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов өлкән яшьтәге һәм хроник чирләре булган кешеләргә коронавирус аеруча куркыныч икәнлеген искә төшерде. Инфекциядән җиңел котылдым дигәннәрнең дә организмнарында үзгәрешләр күзәтелә.

– Илдә, Татарстанда тирәнтен диспансеризация программасы башланды. Ул кешедә коронавирустан соң нинди өзлегүләре калганын, гомумән, аларның барлыгын ачыкларга булышачак. Булган очракта, дөрес төзелгән тернәкләндерү программасы ярдәмгә киләчәк, – дип аңлатты белгеч. – Кызганыч, көн саен чир аркасында югалтулар кичерәбез. Тулаем иркенәю турында уйларга кирәкми әле.

Сүзгә-сүз

Марат САФИУЛЛИН, Федераль салым хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы:

Ничек кенә сәер тоелмасын, әҗәтлеләрнең төп өлешен 25тән алып 60 яшькәчә булган хезмәткә яраклы кешеләр тәшкил итә. Аларның күбесе – машина хуҗалары. Шуңа күрә без Суд приставлары хезмәте һәм ЮХИДИ органнары белән берлектә автомобиль хуҗаларын тоткарлау өчен рейдка чыгабыз. Быел рейд вакытында 24 транспорт чарасын тоткарладык, нәтиҗәдә бурычларның 98 проценты урында ук түләнде.

(«Татар-информ» агентлыгындагы әңгәмәсеннән)

ТОРМЫШТА ИҢ МӨҺИМЕ НӘРСӘ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән: «Тормышыгызны нәрсәдән башка күз алдыгызга китерә алмыйсыз? Иң мөһиме нәрсә?» – дип сорашкан.

75%.........гаилә, яраткан кешем, балалар

34%.........эш

20%.........яңа күнекмә һәм белем

10%.........тәмле ризык

9%...........хәйриячелек

Ике ай чистарынабыз

Татарстанда 1 апрельдән 31 майга кадәр урамнарны чистарту-җыештыру буенча санитария-экологик икеайлыгы үткәреләчәк. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле документка кул куйган. Документ нигезендә, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары үзләре карамагындагы территорияләрне тәртипкә салу планнарын 25 мартка кадәр эшләп расларга тиеш. Шулай ук икеайлыкны үткәрү эшләрен җайга салу өчен оператив штаблар булдырылачак. Елга-күлләрнең су саклау зоналарын, комлыклар, сквер, парк, балалар мәйданчыклары, базарлар, халыкның ял итү урыннары, бакчачылык ширкәтләре, шәхси торак йортлар территорияләрен чистарту күздә тотыла.

Сүз уңаеннан, узган елдагы икеайлык вакытында 400 мең куб метрдан артыграк күләмдә чүп-чар полигоннарга озатылган, 700 меңнән күбрәк агач-куак утыртылган. Чистарынуда 780 меңнән артыграк кеше катнашкан.

kzn.ru

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӨЙЛӘШҮЛӘР ӨСТӘЛЕ ЯНЫНДА

Дөнья сәясәтендә төп вакыйга Украинадагы вазгыять, әлбәттә. Матбугат шул теманы төрләндерә. Бөтен дөньядагы икътисади хәл, социаль тормыш шуңа бәйле чөнки. Бизнес-катлаулар, гади халык түземсезләнеп конфликтның чишелешен көтә, төрле диндәгеләр утның туктатылуын сорап дога кыла. Сәясәтчеләр дә хәтта эшнең тирәнгә китүен аңлады. Вашингтоннан Ак йорт кичә, бездә төн булганда, Россия деэскалация адымнары ясаса (ягъни махсус операция көчләрен чигерсә), санкцияләрне йомшарту турында фикер алышырга әзер булулары хакында сигнал бирде. Бик мөһим хәбәр бу. Байден атом бомбасы шартламас дип уйлый, монысы да начар түгел, димәк, каршы як бу юнәлештә киеренкелекне үстерү ягында түгел.

Мәскәү белән Киев та сөйләшүләр өстәленең утлы мәйданга караганда яхшырак икәнен аңладылар. Якшәмбе көнне үк игълан ителгән сөйләшүләр дүшәмбедә булып узды. Мәскәү сөйләшү өчен бик уңышлы бер моментны уздырды ләкин. Беренче ракеталар оча башлаганда, иртәнге сәгатьләрдә Зеленский, Кремльнең бөтен таләпләрен дә искә алып, сөйләшүләр өстәле янына утырырга әзер иде. Ул бары тик куркынычсызлык гарантияләре генә сорады. Тик Россия җитәкчелеге бу мөмкинлекне югалтты. Беренче курку үткәч, Украина ягы үзен башкача тота башлады. Белоруссия белән Украина чиген бүлүче Припять елгасы ярына бик көттереп, озаклап килде, килеп җиткәч, ятып йоклап та алдылар, диделәр. «Российская газета»ның сишәмбе саны бу турыда: «При этом украинские «источники» не скрывали, что за капризами украинской стороны скрывалось намерение затянуть время, которое якобы работает на них», – дип язды. Чынлыкта вакыт ике якка да зыянга эшли: ут ява, корбаннар арта, икътисади җимерелү көчәя...

Сөйләшүләр өстәле янына Украина ягы оборона министры Алексей Резников җитәкчелегендәге илнең төрле сәяси көчләрен үзенә туплаган делегация белән утырды. Хәтта Россиядә тыелган «Мәҗлес» эшлеклесе, Югары Рада депутаты Рөстәм Үмәров та бар иде. Бу Киевның Кырым картасын да уртага салачагын аңлата. Россия ягын элекке мәдәният министры, хәзер Президент ярдәмчесе Мединский әфәнде җитәкләде. Бу кешенең тарихчы булуы Мәскәүнең тарихи фактларга басым ясаячагын дәлилли иде. Әлегә яклар бер-берсенә кабул ителмәслек таләпләр куйдылар. Киев бар төбәкләрдән дә (Донбасстан һәм хәтта Кырымнан да) Россия гаскәрләрен чыгаруны таләп итә. Мәскәү махсус операция башлар алдыннан куйган таләпләреннән чигенми диярлек. Аңлашыла инде: бу таләпләрдә кисешкән нокталарны табу кыен. Украина хәтта репарация түләүне дә таләп итә, ди «Российская газета». Мединский, ике як та барлык сорауларны карап чыкканнан соң, киләчәктә уртак позицияләрне фаразларлык кайбер нокталар табылды, диде. Россия делегациясенең кайбер башка вәкилләре дә киләчәктә алгарыш булачагына өметләнәләр. Зеленский, сөйләшүләрдә көтелгән нәтиҗәләргә ирешеп булмады, ди, әмма ул да кайбер өметле сигналлар алынуын яшерми. Сөйләшүләр тагын булачак. Илләрнең югары җитәкчелегенә үзара фикерләшергә дә кирәк бит әле. Ике якның да зур компромисслы адымнары сорала. Буласына өметләник.

Россиядә

КИТМӘГЕЗ, АЙ-ТИЧЫЛАР!

Үткән атна ахырында Россиягә каршы кертелгән каты санкцияләр дүшәмбе безне бөтенләй башка дөньяда уятты: финанс тармагы утлы табада сикергән кебек булды, кече һәм эре бизнесның хәле мөшкелләнде, кешеләр банкоматларга чиратка басты, акча юк, дигән хәбәрләр ишетелде. Газета хәбәрчесе бармады ул машиналар янына, чөнки картада түләүләр өчен җитәрлек кенә акчасы бар иде. Беренче шок үтте, әлбәттә. Үзәк банк акча тотрыклылыгын урнаштыру өчен бар көчен сарыф итте. Төп ставка күтәрелде, кайбер банклар инвестицион хисаплардан акча бирүне кыска вакытка туктаттылар. Нәтиҗәдә доллар курсы, бик югары ноктада булса да, тукталды. Биржада валютадан башка берни дә сатылмый, шуңа күрә кыйммәтле кәгазьләр базарындагы хәлне чамалау мөмкин түгел. Чит ил биржаларында Россия компанияләренең кәгазьләре «өчле сальто» ясый ясавын, тик нишләтәсең, монысына безнең финанс хакимиятләре тыкшына алмый.

Тагын бер тармакта проблемалар янартау аткан шикелле хәбәр салды. Илнең иң яхшы ай-ти белгечләре чит илләргә чыгып качу җаен эзли башладылар. Газета хәбәрчесе дүшәмбе Казандагы ай-ти бизнес вәкилләренең чатларда язышканнарын укып, кайберәүләргә киңәшләр дә биреп вакытын уздырды. Эш шунда: SWIFTтан Россиянең иң зур банкларын өзгәннән соң, чит илдән акча алу мөмкинлегенә бетә язды. Программачыларның иң уңышлы төп катлавы исә, кече бизнес рәсмиләштереп, үзебездә утырган килеш чит илләр заказын үти, хезмәт хакын валютада ала. Бу – легаль бизнес, рөхсәт ителә һәм хуплана да хәтта, чөнки, бердән, илгә валюта керә, икенчедән, салым түлиләр. Ике куян берьюлы тотыла. Хәзерге вазгыять бу бизнесны чалгы белән чапкан кебек итте. Әлегә SWIFTтан өзелмәгән банклар аша эш йөртеп була, әмма дә ләкин Америка санкцияләрнең дүртенче пакеты белән яный. Анысы иң катысы, борылырга да урын калдырмый торганы. Аннан соң, ай-ти кече бизнес Тинькофф банк аша йөртә эшен. Дүшәмбе ул да санкцияләр исемлегенә эләкте.

«Мин Дубайда төпләнермен, ахры», «18 мартка Истанбулга билет алдым, гаилә белән шунда күчәбез», «Грузияне иң уңышлы урын дип табам» дигән хәбәрләр килде газета хәбәрчесенә. Грузиядә кече бизнес бөтенләй салымны аз түли икән, мәсәлән. Егетләр бар ягын да исәпкә алалар. Иң мөһиме: тотрыклылык кирәк аларга, иртәгесе көнгә ышаныч кирәк. Чит ил компанияләре күчеп урнашуда ярдәм вәгъдә итәләр.

Әлеге вазгыять аяз көндә ялтыраган яшен кебек булды һәм илнең югары җитәкчелегенә дә тавышы ишетелде. Цифрлаштыру министрлыгы ашыгыч рәвештә чемоданнарын тутыручы ай-тичыларга, илдә калсалар, бонуслар вәгъдә итеп мөрәҗәгать ясады. Эшләгән чорда армиягә алынмаячакларын, өч елга НДФЛ салымыннан азат ителәчәкләрен, 5 процентлы ташламалы ипотека гарантияләде. Бонуслар зур инде зурын, егетләр ничек җавап бирер ләкин.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ИҢ ЯХШЫСЫ – БАЛАЛАРГА

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда яңа перинаталь үзәккә нигез ташын салуда катнашты. Ул шәһәрнең 7 нче клиник хастаханәсе бала тудыру йорты базасында булдырылачак.

Перинаталь үзәк 160 ятак-урынга исәпләнгән. Биредә һәр ел саен 8 меңгә якын балага дөньяга килергә ярдәм ителәчәк. Үзәк Казаннан, шулай ук якындагы районнардан йөкле хатын-кызларны кабул итәчәк.

«Без демографияне яхшырту мәсьәләләрен һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз. Булачак аналарның иминлеге – эшебезнең өстенлекле юнәлешләреннән берсе. Заманча үзәк булдыру бу бурычны сыйфатлы итеп башкару мөмкинлеге бирәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Үзәк яңа туган балаларны реанимацияләү бүлеге заманча сулыш алдыру аппаратлары һәм кювезлар (нарасыйлар өчен инкубаторлар) белән тәэмин ителәчәк. Төзелешне 2023 елның августында төгәлләү күздә тотыла.

Шуннан соң Рөстәм Миңнеханов 7 нче хастаханәнең бала тудыру бүлегендә булды. Биредә ул бүген сабые Зәрия белән өенә чыгарылучы Айзилә Төхвәтуллинаны өченче баласының дөньяга килүе уңаеннан котлады.

Соңыннан Президент Татарстанның бала тудыруга ярдәм итү хезмәте белгечләре белән очрашты. Ул яңа перинаталь үзәкнең технологик яктан иң югары дәрәҗәдә төзеләчәген искәртте.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «KRAVT HOTEL KAZAN AIRPORT» кунакханә комплексын ачуда катнашты. Яңа кунакханә «Казан» халыкара аэропорты һәм «Казан Экспо» күргәзмә комплексы янәшәсендә урнашкан.

Ул 2019 елның февралендә төзелә башлаган. Инвесторы – «ТатКравтИнвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте. Кунакханәнең 9 катында төрле категорияләрдәге номерлар: студияләр, ярымлюкс һәм люкслар, апартаментлар, президент люксы, шулай ук физик мөмкинлекләре чикләнгән кунаклар өчен номер булдырылган. Кунакханәдә берьюлы 500 кешене урнаштырырга мөмкин. Территориясендә автомобиль кую урыннары булдырылган. Кунакханәнең эчке бизәлешендә татар милли бизәкләре кулланылган.

Комплексны төзү «KRAVT GROUP» компаниясенең Татарстандагы тәүге инвестицион проектына әйләнгән. Хәзер инде республикада компаниянең башка проектлары да тормышка ашырыла башлаган.

Яшәеш

Бозга якын килмәскә!

Язгы чорга ышаныч юк! Көннәр җылыта, димәк, сулыклардагы бозга ышаныч бетә. Балыкчыларны, боз өстеннән йөреп юлны кыскартырга яратучыларны Татарстанның кече суднолар буенча баш инспекторы Юрий Венедиктов «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә әнә шул хакта кисәтте.

– Боз өстендә йөрергә яратучыларга да, балыкчыларга да үтенеч бер – бозга ышанып, сулыкларга кермәвегезне сорыйбыз. Көндез кояш нурлары җылысы белән боз өсте эри башлады. Күп кенә сулыклар акрынлап ачыла. Юлны кыскартам дип, елга аша чыгу турында уйламагыз. Бу – гомер өчен куркыныч, – ди Юрий Венедиктов. – Әлегә республикада өч боз кичүе эшли. Әмма көннәр җылы торса, алар да ябылачак.

Безнең халык ярамыйга карамый бит әле ул. Кермә, дигән саен керүчеләр дә бар. Шуның өчен сулыклар янәшәсендә коткару пунктлары эшләячәк. Шушы көннәрдә республикада ун коткару пункты үз эшен башлаячак.

Юрий Венедиктов сулыклар турында сөйләгәндә, көймә һәм катерларны йөртер өчен кирәкле документларны алу тәртибен, аны рәсмиләштерү, исәпкә кую турында да аңлатты.

– Быелдан көймә һәм суднолар өчен электрон билет алып була. Аларга куар-кодлар да бирелә башлый. Көймәңне теркәү өчен дә өйдән чыгасы түгел. Гаризаны «Дәүләт порталы» хезмәте аша тапшырып була. Электрон теркәүнең үз уңайлыгы бар. Көймәне сатып алгач, бер ай эчендә аны теркәү өчен гариза бирергә һәм шуңа 1600 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәнлеккә чекны гына теркәргә кирәк, – ди баш инспектор.

Быелдан көймәләрне теркәү вакыты да кимегән. Элек аны гариза язгач, 14 көн эчендә теркәсәләр, хәзер бу эш 7 көндә башкарыла икән.

– Көймәсе булган кеше аны вакытында теркәргә тиеш. Бер урында теркәп, икенче җиргә күченеп китә икән, көймә хакында да онытмаска кирәк. Узган ел теркәлмәгән 20 көймә хуҗасына беркетмә төзелде, – ди Юрий Венедиктов.

Элек теркәлмәгән кече судно өчен 500 сум күләмендә штраф каралган булса, быелдан аның бәясе артты. Хәзер штраф күләме 15–20 мең сумга җитә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Студентлар урамда калмаячак

Актуаль тема

Чит илләрдә белем алучы яшьләр туган якларына кайтырга мәҗбүр. Украинадагы вазгыятькә бәйле рәвештә Европа вузлары Россия студентларын укытудан баш тарткан. Бу хакта Россия югары белем бирү һәм фән министры Валерий Фальков белән очрашуда илнең Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Татьяна Москалькова әйткән.

Вәкаләтле вәкил белдергәнчә, бүген Франция, Чехия, Бельгия һәм башка илләрнең югары уку йортларында белем алучы яшьләрнең хокукларын яклау буенча чаралар күрелә. Мәгърифәт министрлыгы әти-әниләрне, студентлар укуларын илнең алдынгы вузларында дәвам итә алачак, дип тынычландыра. Тәкъдим ителәчәк уку йортлары арасында Мәскәү, Санкт-Петербург вузлары да бар.

Бездәге хәлләр турында да белештек. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге белдергәнчә, әлегә «Алгарыш» программасы буенча мөрәҗәгать итүчеләр юк. Хәзерге вакытта магистрантларның төп өлеше Германиядә укый. Немец академик алмашулар хезмәте, студентлар программаны ахырына кадәр укыячак, дип ышандырган.

«Китап» радиосының баш мөхәррире Алмаз Миргаязовның улы Ислам Чехиядә белем ала.

– Улыбыз – Прагадагы Ньютон университетының икенче курс студенты. Ул анда бренд-менеджмент белгечлеген үзләштерә. Грант отып түгел, аттестат баллары белән, өстәмә имтиханнар тапшырып укырга керде. Быел болай да өйдән генә торып укый. Коронавирус сәбәпле, яхшы укыган студентларга дистант формасын сайларга рөхсәт иттеләр. Улыбыз безгә: «Чехия Россия студентларын кире кайтару турында карар кабул иткән, әмма әлегә хәбәр иткән кеше юк, мин укыйм», – диде. Кайткан очракта да, авыр кабул итмәячәкбез, урамда калмас дип ышанам. Аларны илдәге вузларга урнаштырачаклар дигән сүзләр әйтәләр. Дәүләт нинди дә булса карар кабул итәргә тиеш дип уйлыйм, – диде Алмаз Миргаязов.

media-kpfu.ru

Татарстанда бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец Россия студентларының туган якларына кире кайту хәбәрен кире какмады.

– Вазгыять авыр, берәү дә мондый хәлләр булыр дип башына да китермәде. Европа гына түгел, Америка вузларында да безнең студентларга уку тыела. Алар гаепле түгел. Бер өлеше – акчага, икенчеләре грант, студентлар алмашы хисабына укый. Проблеманы нинди белгечлек алуларына карап хәл итәргә кирәк. Безгә әле мөрәҗәгать итүчеләр юк, мәсьәләне контрольдә тотачакбыз. Алар белемсез калмаячак. Шулай ук Донбасстан күченеп килүчеләр дә урнаштырыла. Әгәр спорт белән шөгыльләнүчеләр бар икән, аларга шушы юнәлештә дә булышачакбыз. Студентларга болай да психологик яктан авыр. Шуңа күрә әти-әниләре, туганнары үзләрен дөрес тотсын иде. Без укытачакбыз, эшкә урнаштырачакбыз, – диде Ирина Волынец.

Сәрия МИФТАХОВА

ХАЛЫК ӘЙТСӘ, ХӘЛ ИТЕЛӘ

Нәтиҗә

Халык социаль челтәрләр, мәгълүмати технологияләр белән дус хәзер. Кар чистартылмаса да, элмә такталарда хәреф хатасы булса да, урам уты янмаса да, интернет ярдәмгә килә. Цифрлы мохиттә халык белән элемтә ничек көйләнгән? Хөкүмәт йортында шул хакта сөйләделәр.

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрының беренче урынбасары Илья Начвин әйтүенчә, мөрәҗәгатьләр юллау өчен халык иң еш файдаланган мәйданчыклар булып «Дәүләт хезмәтләре» порталы, «Халык контроле» һәм халык арасында сораштыру системалары санала. Беренчесенең ихтыяҗы соңгы арада бигрәк тә артты.

– Портал кирәкле булуын раслады, 2021 елда аннан актив кулланучылар саны 500 меңгә артып, 1,6 млн кешегә җитте. Аның аша башкарылган банк операцияләре (транзакция. – **Ред.**) саны 290 миллионнан 314 миллионга кадәр артты. Портал аша башкарылган түләүләр күләме 4 миллиардка кадәр артып, 30 миллиардны тәшкил итте, – дип сөйләде министр урынбасары. Ихтыяҗ артуы портал тәкъдим иткән хезмәтләр исемлегенең киңәюенә дә бәйле. Әйтик, муниципаль парковка өчен түләү башкармаганга килгән штрафтан аның ярдәмендә котылып була. Мәктәпкә керү, судка язылу өчен чиратка язылырга мөмкинлек бирелә. Быел министрлык алдында социаль әһәмияткә ия булган 253 хезмәтне электрон рәвешкә күчерү максаты да тора. Хәзер республика күләмендә 125 хезмәттән онлайн файдаланырга мөмкин.

– Калган хезмәтләрне тиз арада электрон рәвешкә күчерү генә түгел, максат – хезмәт күрсәтү тизлеген һәм сыйфатын да арттыру, – ди Иван Начвин.

«Халык контроле» системасына килгәндә, ул инде 2012 елдан бирле республика проблемаларын хәл итүнең нәтиҗәле ысулы булып тора. Былтыр система ярдәмендә 83 мең мөрәҗәгать кабул ителгән. 2020 елда бу сан 77 мең тирәсендә булган. Мөрәҗәгатьләрнең үтәлеше дә югары кала – 78 процент.

«Халык контроле»нә күбрәк юл (21879), сәүдә (5021), торак-коммуналь хуҗалык (4328), транспорт (2899), каты калдыклар чыгару (2007), экология (1656) мәсьәләләренә бәйле мөрәҗәгатьләр килә икән.

Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская, халык алдарак атап үткән онлайн мәйданчыклардан тыш, социаль челтәрләрдә дә активлык күрсәтә, ди. Кире элемтәнең әһәмияте турында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та гел искәртеп тора. Хакимият күреп бетермәгәннәргә төртеп күрсәтергә халык ярдәме кирәк тә инде.

– Республикада «Инцидент Менеджмент» дигән система эшләп килә. Аңа министрлыклар да, районнар да, оешмалар да тоташтырылган. Узган ел система 60 мең хәбәр кабул иткән. 2022 елда инде 7 меңләп мөрәҗәгать бар. Мөрәҗәгатькә җавап бирү вакыты да үзгәрә. Элек 18 сәгать булса, хәзер 3 сәгатьтән артмый, – диде Сәрия Сабурская.

Шушы система ярдәмендә халыкның нинди зарлары хәл ителгән соң? Әйтик, Югары Осланда чүп чыгару, Лениногорскида ишегалдын кардан чистарту, Мамадышта өй түбәсеннән кар төшерү кебек мәсьәләләр.

Халык үз соравына җавапны шул тармакка бәйле хакимият вәкиленнән дә көтә. Бу җәһәттән Сәрия Сабурская халык мөрәҗәгатьләре белән иң яхшы эшләүче министрлыкларны телгә алды. 2021 елда Яшьләр эшләре, Сәнәгать һәм сәүдә, Экология һәм табигать ресурслары, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыклары алдынгылар исемлегендә икән (мөрәҗәгатьләр үтәлеше – 100 процент). Сәламәтлек саклау тармагы азга гына калышкан (98 процент), аның артыннан Министрлар Кабинетының ветеринария идарәсе, Эчке эшләр министрлыгы килә (94әр процент).

Республикада татар телендә элмә такталарда хаталар ачыклау буенча конкурс башланды. Ул 1 марттан 1 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлгән барлык кешеләр дә бу конкурста катнаша ала.
Шартлары мондый: «Халык контроле» системасының кушымтасын телефонга урнаштырырга, теркәлү узарга, «Атамалардагы хаталар» («Ошибки в названиях и надписях») категориясен сайларга кирәк, хата табылуы турында мәгълүматны фотосурәт белән бергә җибәрергә кирәк.
Оештыручылар конкурс нәтиҗәләре буенча 10 җиңүчене билгеләячәк. Узган ел да мондый конкурс оештырылган иде. Хәтерегездә булса, җиңүче булып Мәскәү кешесе танылды. Ул татар телендәге атамаларда 2,5 меңнән артык хата тапкан иде.

nurlat-tat.ru

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТАТАРЧА ДӘРЕСЛЕК ЯЗУЧЫ МАКСИМ КУЗНЕЦОВ:

«ҮЗ ТЕЛЕҢНЕ БЕЛМӘҮ – ОЯТ»

Үрнәк

Санкт-Петербургта яшәүче рус егете Максим КУЗНЕЦОВ редакциягә татарча хат язган. «Газетада чыккан әңгәмәдә галим Алексей Арзамазов мине даһи дип телгә алган. Хәзерге вакытта татар теле дәреслегемне тулыландырам. Бу китабымның Казанда дөнья күрәчәгенә бик өметләнәм. Миңа 25 яшь кенә булса да, монысы язган китапларымның өченчесе булыр. Башка телләр буенча да дәреслекләр язарга җыенам. Мин дә, Алексей кебек, 12 тел беләм һәм белемнәремне башкаларга өйрәтергә хакым бар дип саныйм», – дип, газетаны җибәрүне сораган ул. Максим белән татар телен ничек өйрәнүе, аны саклау турында сөйләштек.

Максим Ижау шәһәрендә туган. Санкт-Петербургта мәктәп, университет тәмамлаган. Әмма әле беркая да эшкә урнашмаган икән. Фин теле курсларында укыта алыр идем, ди. Удмурт яки вепс телләрен дә өйрәтергә риза, тик шәһәрдә андый курслар рәсми рәвештә оештырылмый икән. Хәзерге вакытта төрле текстлар эшкәртү, тәрҗемә итү белән мәшгуль.

:: Максим, татар теле белән ничек кызыксына башладың? Нәселегездә татарлар юктыр бит? Санкт-Петербургта татарча аралашырга мөмкинлек бармы?

– Әти-әнием – руслар. Мин – гаиләдә бердәнбер бала. Нәселемдә татарлар бар. Ижауда яшәүче 77 яшьлек Галина әбием татарча белә. Тик ул җангыр җава, урамда җөрмә дип сөйләшә. Шуңа күрә бер-беребезне аңлый алмыйча торган чаклар да еш була. Татар телен аңа әнисе – Асия әби өйрәткән. Ул миңа 15 яшь чакта бакыйлыкка күчте. Кызганыч, ул вакытта татарча бер кәлимә сүз дә белми идем. Татар теле белән бары 19 яшьтә генә кызыксына башладым. Мәктәптә укыганда татарча өйрәнәсем килсә дә, вакыт җитмәде. Рус теленнән бөтенроссия олимпиадасына әзерләнергә кирәк иде. Бу олимпиадада җиңеп, университетка имтиханнарсыз укырга кердем. 2016 елда шәһәрнең К. Насыйри исемендәге Мәгариф һәм мәдәният үзәгендә татар теле курслары оештырылганын ишеттем. Альбина Фәхразыева – минем беренче татар теле укытучым. Шулай итеп, татарча өйрәнә башладым. Тәҗрибә туплау өчен җәен Ижауга кайтып, әбием белән татарча сөйләшәм, «Яңарыш» редакциясенә барып, татарча газеталар алам. «Ана теле» онлайн мәктәбенең дә ярдәме тиде. Татарчаны алты ел өйрәнәм инде. Кайвакыт туктап та торам, чөнки эшләрем бик күп. Дөрес, кыенлыклар бар әле. Мәсәлән, тезмә фигыльләрдә аптырап калам. Грамматиканы яхшылап өйрәнәчәкмен. Әмма грамматиканы аңлау тел өйрәнүдә бердәнбер мөһим әйбер түгел. Лексика, ягъни сүзләр белү кирәк. Мин беркайчан да ятлап өйрәнмим, кирәклесе үзе хәтердә кала. Тел онытылмасын өчен аралашырга кирәк, менә анысы җитми. Татар дусларым, танышларым бар, ләкин алар белән бик сирәк аралашам. Элекке сыйныфташым Наилә белән мәктәптә укыганда әллә ни еш аралашмасак та, хәзер дуслыгыбыз ныгыды. «Яңа Гасыр» телеканалының тапшыруларын карыйм, интернет аша «Болгар радиосы»н тыңлыйм, хәбәрләр укыйм. Татар җырларын бик яратам. Энколово авылында оештырылучы Сабантуйда дүрт тапкыр булдым. Җырлар тыңлап, көрәш карап, пылау ашап, дуслар белән аралашып кайтам.

:: Нинди телләр беләсең?

– Рус, татар, удмурт, башкорт, фин, карел, вепс, водь, ижора, алман, кытай һәм төрек телләрен. Вепс, водь һәм ижора телләре – Ленинград өлкәсендә яшәүче күптәнге кече халыкларның, ягъни вепсларның, водьларның һәм ижораларның телләре. Вепс телен бик яхшы беләм, чөнки нәкъ әлеге телдән бик яхшы үзөйрәткеч бар. Бу китапны 2012 елда тапкач, авторы белән очраштым. Һәр кече милли тел өчен яхшы үзөйрәткеч булу – бу телнең саклану гарантиясе дип уйлыйм. Аны укып, һәр кеше кызыксындырган телне өйрәнә алыр иде, шулай иткәндә телләр дә яшәр.

Үзем исә төрлечә укыйм: мәсәлән, водь һәм ижора телләре буенча яхшы әсбаплар юк диярлек, бу телләрне текстлар һәм грамматикалар укып кына өйрәнеп була; алар фин теленә охшаш. Фин телен белмичә, ижора һәм водь телләренең нечкәлекләрен аңламыйсың. Фин һәм вепс телләрен белү миңа карел телен аңларга ярдәм итә. Башкортча өйрәнү теләге тугач, миңа бер дәреслекне актарып чыгу җитте. Башкорт һәм татар телләре дә берберсенә бик охшаш. Хәзер башкорт кызы белән язышам. Бер-беребезнең хатларыбызны түземсезлек белән көтәбез. Төрле телләрдә язышу бик кызык һәм телләр өйрәнү өчен файдалы. Кайвакыт кытайча да язышырга тырышам, ләкин бу телне өйрәнү бик кыен. Мин телләр белән генә түгел, төрле халыкларның мәдәниятләре, тарихы һәм хәзерге тормышы белән дә кызыксынам. Үземне актив кеше дип саныйм, һәрвакыт нәрсә белән дә булса шөгыльләнергә тырышам: йә нәфис әдәбиятны вепсчага тәрҗемә итәм, йә Карелиядән фин телендәге газета укыйм, йә татарча хәбәрләр тыңлыйм, дусларга хатлар һәм фәнни журналларга мәкаләләр язам.

:: 25 яшьтә 12 тел беләсең. Үзеңне даһи дип саныйсыңмы?

– Кешене даһи дип башка кешеләр әйтә ала дип уйлыйм. Мәсәлән, минем өчен Алексей Арзамазов – даһи. Ул сезгә 20 яшьтә удмурт теле үзөйрәткечен бастырганы турында нигәдер әйтмәгән, 30 яшьтә бастырган үзбәк теле дәреслеген генә әйткән. Удмурт телендәге шигырьләр җыентыклары, берничә монографиясе, бик күп фәнни мәкаләләре бар аның. Минемчә, яшьли фән докторы булуы да гаҗәеп һәм хөрмәткә лаек. Гомумән, даһи – бәяләү категориясе; әгәр башкалар сине даһи дип санаса – син даһи буласың.

Мине тагын эстон, швед, исланд, гарәп, фарсы телләре кызыксындыра. Гарәп телендә миңа күп таныш сүзләр очрар дип уйлыйм, чөнки күбесе татар әдәби теленнән дә алынган. Россиядәге башка халыкларның телләре – мари, чуаш, коми, якут телләре дә кызык. Татар теле дәреслегемне язып бетергәч, удмурт һәм башкорт телләре буенча үзөйрәткечләр язарга ниятлим.

:: Ни өчен татар теле дәреслеге чыгарырга булдың?

– Бервакыт татар теле курсларына Татарстан китап нәшрияты вәкилләре килде. Алардан укытучы Альбина: «Мин кулъязмамны сезгә җибәрсәм, аны карап тикшерерсезме?» – дип сорады. Мин аннан: «Кайсы кулъязмагызны?» – дип кызыксындым. Ул татар теле буенча кечкенә әсбап язарга җыенуын әйтте. Мин аңа ярдәм итәргә булдым, киләчәк дәреслегемнең беренче дәресен яздым. Һәм ул, гаҗәпләнеп: «Синең татар теле дәреслеген язарга зур сәләтең бар!» – диде. 2016–2017 елларда дәреслегем өчен унике дәрес яздым, аннан текстлар белән тулыландырып, 2020 елда рецензияләү өчен Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрдем. «Бар хаталарны да төзәтеп чыгарга кирәк, шуннан соң гына дәреслек бастырыла ала», – дигән җавап алдым. Быел мин интернетта Алексей Арзамазов турында укыдым, шуннан аның белән танышып киттек. Ул да татар теленнән үзөйрәткеч язган икән. Казанда Фән көне уңаеннан уздырылган яшь галимнәр белән очрашуда Рөстәм Миңнехановка татар теленнән яңа үзөйрәткечләр бастырырга тәкъдим иткән. Татарстан Президенты риза булгач, быел ике дәреслек нәшер ителер дип ышанам. Шуның өчен миңа дәреслегемне тулыландырып, Арзамазов җитәкчелегендәге фәнни лабораториягә җибәрергә кирәк. Телне мөстәкыйль рәвештә өйрәнергә теләүчеләргә беренче чиратта татарча яхшы үзөйрәткеч, басма яки электрон сүзлек (ул бик кечкенә булмасын) табып шөгыльләнергә, теле- һәм радиотапшырулар тыңларга, газеталар укырга киңәш итәм. Һәм мөмкинлек булган саен аралашырга тырышырга кирәк.

:: Туган телне белмәү – оятмы?

– Үз халкыңның телен белмәү, минемчә, оят. Ләкин моңа һәр кешенең үз фикере, һәр кешенең нәрсәдер белмәскә хокукы бар. Телне өйрәнергә мәҗбүр итү дөрес түгел. Кешенең кызыксынуы һәм теләге тусын өчен шартлар булдырырга кирәк. Мин Татарстанда шундый шартлар тудырылган, ләкин тулысынча түгел дип әйтер идем. Татар телевидениесендә кызыклы тапшырулар күбрәк күрсәтелсен, аларның сыйфаты югарырак булсын иде. Нигә дөнья хәбәрләре турында татарча сөйләмәскә? Нигә балалар өчен кызыклы китапларны татарчага тәрҗемә итеп бастырып чыгармаска һәм аны укучыларга бүләк итмәскә? Мәктәпләрдә дә балаларны тел белән кызыксындырырга кирәк. Һәм, әлбәттә, кешенең татар телен өйрәнергә мөмкинлеге булырга тиеш. Минем үзөйрәткеч телне өйрәнергә теләүчеләргә шундый мөмкинлек бирер дип өметләнәм.

:: Казанга килгәнең бармы? Күченеп килергә җыенмыйсыңмы?

– Казанда бер тапкыр да булганым юк. Бу – минем зур хыялым. Сезнең шәһәр искиткеч, аңа бик тиз гашыйк булырга мөмкин дип уйлыйм. Минем Казанны да, Изге Болгарны да, Зөяне дә күрәсем килә. Казанга күченеп килү турында уйламадым, ләкин яхшы һәм кызыклы эш тәкъдим итсәләр, нигә килмәскә?

Сәрия МИФТАХОВА

БАЛГА ДЕГЕТ САЛУЧЫ ТАБЫЛЫП ТОРА

Авыл кешесе үз теләге белән килсен өчен китапханәләр менә шундый булырга тиеш – Балтач районының Смәел авылы китапханәсен күргәч, күңелдә туган беренче фикер бу. Китап укучылар юк инде ул, дип зарланып, үткән гасырның 60–80 нче елларында китапханәләр гөрләп тора, кеше чират торып китап укый иде, дип, үткәннәрне сагынудан мәгънә юк. Әлеге авыл китапханәчесе Гөлфинә Әхмәдиева кебек, булган һәр мөмкинлектән файдаланырга, тәвәккәлләргә генә кирәк. 20 ел эшләү дәверендә әнә шуңа ышанган ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– 2018 елда без республикада үткәрелгән конкурста катнаштык һәм «Иң яхшы авыл китапханәсе» дигән номинациядә җиңеп, 100 мең сум акча оттык, – ди Гөлфинә. – Бу акчага китапханәгә зур телевизор, принтер, җиһазлар алдык. Бер җиңгәч, тагын катнашасы килә башлады. Республика грантын отарга иде, дип хыялландык. Тик бу конкурста катнашу өчен тиешле шартларны үтәргә кирәк, ә алары безнең көчтән генә килә торган түгел иде.

Әмма, бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, диләрме әле? Үткән гасыр урталарында төзелсә дә, чоры өчен генә түгел, бүген дә мәһабәт бина булып, колонналары белән кукраеп утыручы Смәел авылы мәдәният йортына 2020 елда капиталь ремонт үткәрелә. Шул чакта китапханә өлеше дә заманчага яңартыла. Грантта катнашуның төп шарты – китапханә яңартылган, ремонтланган, заман таләпләренә җавап бирергә тиеш була. Гөлфинә инде бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмый. Үткән ел алар әлеге мәртәбәле грантны ота – китапханәгә 2,5 миллион сумлык сертификат бирелә. Бу суммага компьютерлар, мультимедиа җиһазлар, мебель, балалар өчен интерактив идән, ноутбук, принтерлар, интерактив такта һәм 1971 китап, заманча әдәбият комплектлары, энциклопедияләр кайтарыла.

– Әлеге грантны оту өчен бик күп хезмәт куйды. Безнең иң тырыш, булдыклы китапханәчеләребезнең берсе ул, – ди Гөлфинә турында район үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре җитәкчесе Резидә Зарипова. – Бик күп чаралар үткәрә. Ковид белән бәйле тыюлар чорында ул авыл тарихын, аның кешеләрен, көнкүреш гореф-гадәтләрен чагылдырган ике дистәдән артык видеоязма төшерде һәм туплады. Алар бик бай мәгълүматлы һәм китапханәгә килгән һәркем кызыксынып карарлык. Инде кайтарылган заманча җиһазлардан да оста файдалана. Иҗади эшли белүе белән аерылып тора. Бу яңалыкларның нәтиҗәсе дә без көткәнчә булыр дип ышанабыз.

Без барган көнне китапханәгә заманча җиһазлар кайткан, алар әле җыелмаган иде. Әмма инде кайтарылган заманча җиһазлар барысы да «эшкә җигелгән» һәм алар балаларда да, өлкәннәрдә дә бердәй кызыксыну уяткан булып чыкты.

– Балалар мәктәптән кайтышлый ук керә, кичләрен тагын җыйналып киләләр. Аларны бигрәк тә интерактив идән, интерактив такта, интерактив уеннар җәлеп итә. Берсеннән-берсе матур, сыйфатлы өр-яңа китапларны, бигрәк тә энциклопедияләрне күп сорыйлар. Яшьләр дә килә. Алар өчен дә кызыклы китаплар күп. Әлегә өлкәннәр дә бик кызыксына. Тик алар барысы да татарча китаплар сорый. Кызганычка, безгә бирелгән яңа китаплар арасында татарча китаплар юк, – ди Гөлфинә.

Гаҗәп, шулай бит? 1971 китап арасында бер генә данә дә татарча китап булмавы, чыннан да, гаҗәп. Аптырагач: «Сез әллә Россия грантын оттыгызмы?» – дип кабатлап сорадым. Ялгыш аңлаганмындыр дигән өмет кенә акланмады. Хәер, барысы да әйбәт булса, безнеңчә буламыни инде ул? Бер мичкә балга бер кашык дегет салмый калып була димени? Өстәвенә үзебез үткән ел Телләрне үстерү елы дип шау килдек. Шушы кадәре эшләнгәч, чеп-чи татар авылына, һич югы яртысына татарча китаплар кайтарту бер генә кешенең дә башына килмәдеме икәнни?! Балалар өчен дә татарча китаплар бик кирәк ләбаса.

Хәер, монысы төзәтеп булмаслык хата түгелдер. Әлегә яңа китаплар киштәләргә тезелмәгән. Аларның бер өлешен булса да татарчага алыштыру хәл итмәслек проблемадыр дип уйламыйм. Мөгаен, теләк кенә кирәктер.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

МАРТ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ

Яңалык

Корал әйләнешенә контроль көчәйтелә, хезмәтне саклау өлкәсендә закон яңартыла, авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдә йортлар төзү мөмкинлеге ачыла.

Корал турында

«Корал турында» һәм «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында»гы Законның яңа нигезләмәләре үз көченә керә. Алар корал әйләнешенә контрольне көчәйтүгә, шул исәптән сәламәтлегендә тайпылышлары булган кешеләр (медицина каршы килүләренә ия булучылар) өчен корал сату һәм йөртүне чикләүгә юнәлдерелгән. Медицина каршы килүләре исемлеген Хөкүмәт раслаячак.

Эш урынында иминлек көчәйтелә

Хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген кайгырту көчәйтелә. Хәзер эш урынында хәтәр килеп чыгу ихтималы даими өйрәнеп торылырга, хезмәткәрләргә бу хакта вакытында белдерелергә һәм мондый очракларда эш туктатып торылырга тиеш. Шул ук вакытта производство тик торган вакытта эш урыны да, хезмәт хакы да сакланып кала. Моннан тыш эш бирүчеләрнең үз производствосында, җайланмалар һәм приборлардан файдаланып, хезмәт законы нормалары үтәлүеүтәлмәвен мөстәкыйль бәяләү хокукы барлыкка килә.

Инвалидны эшкә алырга

«Мәшгульлек турында»гы Законның яңа статьясы үз көченә керә. Инвалидларны эшкә алуга квота билгеләү турында ул. Шулай итеп, Россия субъекты законында 200дән артыграк кеше эшли торган оешма яки предприятиедә хезмәткәрләрнең гомуми санының 2–4 проценты күләмендә квота билгеләнергә мөмкин. Ә инде 35тән 100 кешегә кадәрге хезмәт коллективында иң зур квота 3 процент тәшкил итә.

Адвокат имтихан бирә

1 марттан «Россиядә адвокат эшчәнлеге турында»гы Законның яңа нигезләмәсе үз көченә керә. Ул бердәм автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша, адвокатларга, квалификацияләрен ачыклау өчен, электрон рәвештә язмача имтихан үткәрүне күздә тота.

Кырда йорт төзеп була

Фермерларга, гомумән, авылда яшәүчеләргә кыр-басуларда, ягъни авыл хуҗалыгы максатындагы җирләрдә үзләренең милкендәге җир кишәрлегендә торак төзүгә рөхсәт бирәчәкләр. Ләкин шартлары бар. Беренчедән, төзелеш җир кишәрлегенең гомуми мәйданының 0,25 процентыннан артмаска, икенчедән, йортның гомуми мәйданы 500 квадрат метрдан артмаска тиеш.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итү идарәсенең иҗтимагый үсешне мониторинглау һәм фаразлау бүлеге мөдире **Гайнетдинов** Рөстәм Бәдретдин улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең бию ансамбле балет артисты **Галиев** Илнур Нәкыйп улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Нурлат балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең вокал классы буенча укытучысы **Әхмәтҗанова** Роза Ирек кызына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Авылара үзәк китапханә» муниципаль бюджет учреждениесенең 10 номерлы филиалы – Келәнче авылы китапханәсе методисты **Әхмәтҗанова** Алсинә Салихҗан кызына, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе бүлеге – В.И.Ленин музей-йорты мөдире **Басова** Татьяна Ивановнага, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту часте буенча урынбасары, скрипка классы буенча укытучысы **Гыйлаҗева** Тәскирә Мәэмүн кызына, Казан шәһәренең «11 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең баян классы буенча укытучысы **Голуб** Татьяна Евгеньевнага, Омск өлкәсенең «Мәдәният» төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте иҗтимагый оешмасы Советы рәисе **Миңнеханов** Радик Миңнегали улына, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең заманча этносәнгать музее мөдире **Нигамаева** Зилә Салих кызына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Сәлахова** Гүзәлия Салих кызына, Казан шәһәренең «4 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Урасхуҗин** Айрат Әмир улына, шәхси эшкуар **Харисов** Айрат Зөфәр улына, Казан шәһәренең «8 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең теоретик дисциплиналар һәм гомуми фортепиано укытучысы **Шаронова** Ирина Сергеевнага, «Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык күрсәтү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең яшьләр белән эшләү буенча белгече **Шешолина** Любовь Михайловнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире **Макаров** Глеб Сергеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Идел буе электр челтәрләре» филиалы Лаеш электр челтәрләре районы башлыгы **Бәхтиозин** Наил Рәүф улына, «ЖилЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галәүтдинов** Әхәт Насыйх улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Спорт

ak-bars.ru

Былтыр кысканны быел отасы

Тагын «Авангард». Узган ел «Ак барс» плэй-оффтагы чыгышын Омск хоккейчыларына җиңелү белән тәмамлаган иде. Гагарин Кубогы өчен быелгы көрәшне якташларыбыз янә шул ук командага каршы уеннар белән башлый. Бүген узасы тәүге очрашу алдыннан Казан хоккейчыларына Президент Рөстәм Миңнеханов та уңыш теләде. «Ак барс»тан ни өмет иткәннәре сер түгел. Килеп чыкса, хәтта Данис Зарипов та үз сүзләреннән баш тартырга мөмкин.

Хәтерләсәгез, «Ак барс» белән «Авангард» узган ел Көнчыгыш конференциясе финалында очрашты. Бик кискен каршылык булды ул. Омск уенчысы Алексей Емелинның сәер рәвештә авырып китүе, аннары аның организмында наркотик табылуы турындагы имеш-мимешләр, Казан командасында лидер дип саналган чит ил хоккейчыларының кәшәкә тота алмый башлавы – кыскасы, көрәш боздагы уеннар белән генә чикләнмәде. Серия 7 очрашуга сузылды, көндәшләр үз тамашачысы алдында җиңә алмый азапландылар. Хәтта хәлиткеч җиденче матчта да җиңүче бары овертайм, ягъни өстәмә вакытта гына ачыкланды. Ахыр чиктә Омск командасы өстен чыкты һәм соңрак төп финалда ЦСКАны да җиңеп, үз тарихында тәүге тапкыр Гагарин Кубогы иясе булып танылды.

Узган ел көндәшләр финалга чыгу өчен көрәшсә, быел аларга плэй-оффның беренче өлешендә үк очрашу насыйп булды. Дөресрәге, насыйп иттеләр. Ник дигәндә, гадәттә, плэй-оффта кемнең кем белән уйныйсы даими чемпионат йомгаклары буенча ачыклана. Әмма быел күп гадәтләрдән баш тартырга туры килде. Башта әлеге ярышны вакытыннан алда туктаттылар. «Ак барс» турнир таблицасында өченче урында туктап калды, димәк, алтынчы баскычтагы «Сибирь» белән уйнарга тиеш иде. Әмма КХЛ түрәләре башка карар чыгарды: командалар уйнаган очрашулар саны төрлечә, шуңа күрә җиңү күрсәткечләрен процентларга күчерергә кирәк. «Ак барс»ныкы 68,75% булды. Дүртенче урындагы «Салават Юлаев»ның очколары 4кә азрак, әмма уеннары да азрак икәнен исәпкә алгач, Уфа командасының күрсәткече 68,88% булды. Әнә шул кечкенә генә аерма аркасында «Ак барс»ка гамәлдәге чемпион «Авангард»ка каршы уйнарга туры килә. Көчле команда. Икенче яктан, Гагарин Кубогы турында хыялланасың икән, көчле көндәшләргә каршы барыбер уйнарга туры киләчәк.

«Ак барс»та былтыргы җиңелүдән сабак алганнармы? «Узган елгы серияне оныттык инде. Үч алу турында гына уйлап утыра алмыйбыз бит. Һәр команданың җиңәсе килә. Былтыргы уеннардан соң нәтиҗә чыгардык. Кайда нәрсә җитешмәгәнен ачыкларга тырыштык, – ди Казан командасының баш тренеры Дмитрий Квартальнов. – Быел да уеннар кызык булыр дип уйлыйм. Без – «Авангард»ны, алар безне белә. Әмма плэй-офф озакка сузылган тәнәфестән соң башлана. Әлбәттә, әзерлек уеннары уздырдык, әмма аларда ул кадәр үк кискенлек юк. Плэй-оффта уңыш булсын өчен бәхет тә кирәк, капкачылардан да күп нәрсә тора. Быел үз бозыбызда җиңәргә тырышачакбыз».

Плэй-офф җитте исә, Дмитрий Квартальновның көчле командаларда ничә ел эшләп тә, Гагарин Кубогын ота алмаганын искә төшерәләр. Быелгы сезон ахырында аның «Ак барс» белән килешүе тәмамлана. Димәк, алдагы язмышы плэй-оффка бәйле. Квартальновтан аермалы буларак, Казан командасы капитаны Данис Зариповның Гагарин Кубогын 5 мәртәбә тотып караганы бар. КХЛда башка мондый уенчы юк! Әмма сезон алдыннан Данис соңгы елын уйнаячагын әйткән иде. Дөрес, ике көн элек журналистлар белән очрашкач, фикере үзгәрергә мөмкин икәне сизелде.

– Биш ел элеккеге кебек уйный алмаячагымны аңлыйм. Әмма командага файда китерү, егетләрне туплап тору өчен барысын да эшләячәкмен. «Ак барс» инде өченче ел рәттән Гагарин Кубогын ота алмый. Мондый команда җиңүсез бу кадәр озак торырга тиеш түгел, – ди ул. – Карьераны тәмамлауга килгәндә, башымны чит әйберләр белән катырасым килми. Әлегә сүзем үз көчендә, үзгәрешләр юк. Гагарин Кубогын отабыз икән, карарбыз, Алла боерса.

Плэй-оффтагы тәүге уен алдыннан «Ак барс» командасы белән Татарстан Президенты да очрашты. «Бу уеннар җиңел булмаячак, чөнки барысы да җиңәргә тели. Әмма безнең команданың потенциалы зур һәм иң югары баскычка күтәрелү мөмкинлеге бар. Узган ел җиңүгә аз гына җитмәде. Әмма барыбер яхшы уйнадыгыз. «Ак барс» – республика командасы. Сезнең өчен һәрвакыт җан атачакбыз», – диде ул. Капитан Данис Зарипов Рөстәм Миңнехановка клубның яңа логотибы төшерелгән джерси бүләк итте. Элеккеге логотипны 1995 елда ук ясаганнар иде, инде искергән, диләр. Яңасы яңа җиңү китерсен!

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ГАП-ГАДИ ИЛДАР

Шөгыль

Танышымның оныгы туды. Бүләк итим дип, бишек эзли башлады бу. Ярдәмләшү йөзеннән мин дә интернетка кереп киттем. Бишек тә таптым, беррәттән бу илаһи матурлыкның авторы Илдар Гадиев белән сөйләшеп тә алдым. Нәрсәсе белән җәлеп итте дисезме? Сәхнәне остаханәгә алыштыруы гаҗәбрәк тоелды. Сөйләшә торгач, алай ук түгел икәнлеге дә ачыкланды.

– Ташламадым мин сәхнәне. Җыенмыйм да. Башта рәссам һөнәрен үзләштергән идем, аннан Сәнгать институтының режиссура факультетында укыдым. Гомерем буена сәхнәдән төшмәдем. Фамилиям Гадиев булганга, «гап-гади Илдар» дигән кушамат та тактылар үземә. Татарстанның халык артисты Булат Сәлахетдинов белән концертлар алып бардык. Азнакай районының Татар Шуганы авылында Шәфәгать Салихов белән бергә уйнап үстек. Чаллыга ул чакырган иде. Бергәләп эшләдек. Рөстәм Хәйруллин, Гөлдания Хәйруллина кебек җырчылар ул вакытта Төзүчеләр мәдәният йортында эшләде. Татар яшьләренең «Кыйбла» клубын оештырдык. Резедә Шәрәфиева, Равил Галиев, Ринат Хәмәдиев зур сәхнәгә шуннан юл ярдылар. Чаллы язучыларының «Җидегән чишмә» клубында да әдәби кичәләр оештырдык. Шөгыльләрем күп минем. Барысы да иҗат белән бәйле. Курайда да, тальянда да уйныйм. Кайчагында, нинди көй соң бу, дип сорыйлар. Ә мин үзем дә белмим. Көйләр күңелемнән ургылып чыга. Үзем өчен генә шигырьләр дә язам. Картиналар иҗат итәм. Мәктәптә укыганда ук сырлап-сырлап, нәрсә икәне дә аңлашылмый торган рәсемнәр ясап утыра идем. Укытучыларның сөйләгәне башка да кермәгән кебек. Ә шул рәсемгә әллә никадәр вакыт үткәч карасам, сүзләренә кадәр искә төшә. Бервакыт килеп җитте шундый вакыт: агач сырлап утыра башладым. Әмма сәхнәдән китмәдем. Пандемия чире концертларны туктаткач, Фән Вәлиәхмәтов белән эшли башлаган идем. Галәмәт тә үзенчәлекле кеше ул. Менә тормышлар җайланып китсә, планнарыбыз бар әле: концертлар куярбыз дип торабыз.

:: Агач сырлау дип бик гади генә әйтәсез кебек?

– Агачны уеп, чокып ясау дип тә әйтәләр инде аны. Минем үземә сырлап утырам кебек тоела. Рәсем ясаган кебек. Башта картиналар өчен рамнар ясадым. Чөнки үзем иҗат иткәннәрен урнаштырырга кирәк иде. Сырлый торгач, бик матур әйберләр килеп чыга. Сәгатьләр, таяклар, тартмалар… Ясаган берсен бүләк итеп барам. Җәвит Шакиров белән бергә укыган идек. Аның юбилеена сандык бүләк иттем. Баштарак мин сандыкны иске-лек калдыгы, беркемгә дә кирәкмидер дип уйлый идем. Баксаң, кирәксенүчеләр күп икән. Әле, ул кадәрле сырлап утырмасагыз да ярый, дигән булалар. Ә мин бер үк төрле ике әйбер ясый алмыйм. Күптән инде кулыма 1928 елда нәшер ителгән «Татар орнаментлары» дигән китап килеп кергән иде. Анда нинди генә бизәкләр юк! Бик илһамландыра, барысын да үз кулларым белән ясап карыйсы килә. Фәлән вакытка өлгертәм, дип вәгъдә дә бирмим. Бернинди станокларым да юк. Төп эш коралым – русча резак дип аталучы пычак. Бервакыт шулай, кызыбыз кияүгә чыга дип, гозерләп сандык ясап бирүемне сорадылар. Ризалаштым. Бәясен дә әйткән булдым. «Ник син әйберләреңне шул тикле арзанга сатасың?» – дип шаккаттылар. Сата белмим мин. Кем белә, бәлки дөнья өйрәтер әле.

:: Материалларны кайдан юнәтәсез?

– Төрле җирдән. Агач сайлау ул – бик нечкә эш. Аның составын, үзенчәлеген белергә кирәк. Бервакыт күршем, Илдар, бездә 1951 елда эшләнгән иске агач караватят ята, сиңа кирәкмиме, ди. Карыйм: йомшак, ярылмый торган агачтан ясалган. Соңыннан, нишләп караватит итеп кенә калдырмадым икән дип, үкенеп тә йөрдем әле. Базар, кибет тирәсеннән җиләк-җимешләр тутыру өчен файдаланылган агач тартмалар алып кайтам, чөнки аларның зыяны юк. Рам ясарга бик уңайлы. Төссез лак белән буягач, ялтырап китәләр. Агачны, чыннан да, бик белеп кулланырга кирәк. Мәсәлән, бишекне юкәдән генә ясыйлар, чөнки аның исе килми. Каен бик каты, усак ярылып китә. Нарат, чыршыдан сумала исе килә. Бервакыт шулай берәүгә нарат агачыннан сандык ясарга туры килгән иде. Киемнәрен таслап салып куйган бу. «Бер киememne дә кия алмыйм, исе килә», – дип зарланып туя алмады. Хәзер сандыкларны эчке ягыннан кызыл бәрхет белән тышлыйм. Кызыл төс байлык чакыра, дигән гыйбарә бар бит татар халкында. Кечерәк итеп тә ясыйм. Туйларда аны котлау открыткалары, бүләкләр салу өчен кулланалар.

:: Мондый осталык барыбер балачактан киләдер?

– Әллә ни майтарганымны хәтерләмим. Бервакыт шулай Хөсникамал әби, агач сырлап утырган буласың, миңа орчык ясап бир әле, дигән иде. Бик тырыштым. Тиз, тигез әйләнә орчыгың, дип әби бик мактады. Әтием, аның энесе Сәләхетдиннең кулыннан килә иде. Ул вакытта сатып алырга юк бит. Караватлар, өстәл-урындыкларны, гомумән, нәрсә кирәк – барысын да үзләре эшләделәр. Минем әни тегүче иде, бөтен авылны киемле итте, әти заготконторада эшләде. Димәк, минем бөтен әйберем булган. Шуңа күрә зур эшләргә тотынмаганмын да, ахры.

:: Сез авыл малаемы?

– Авылдагы бәләкәй өем – остаханәм. Яшьрәк чакта авылда төпләнергә җыенган кешеләргә шакката торган идем. Олыгайган саен туган җир тарта икән. Шунда кайтып китәргә генә торам. Чаллыда балалар, оныклар яши бит инде. Балалар бакчасына, мәктәпкә, төрле түгәрәкләргә дә йөртәсе бар. Хатыным әрләгән була, качып йөрисең, ди. Ә мине һаман да шул бәләкәй йортым үзенә тарта. Шуны ремонтлап куясы бар әле. Һич кенә дә кулым җитми. Ялкаурак, ахры, мин. Төннәр буе йокламый әллә ниләр уйлап ятам. Башка әллә нинди фикерләр килә. Пенсиягә чыгып, азрак вакыт үткәч, әллә нинди эшләргә тотынырмын, шул вакытны көтеп йөрим кебек тоела.

:: Ялкау дигәнегез белән килешеп булмый. Эшләгән эшләрегез бихисап.

– Күңелне иркәләп торырлыклары да бар инде. Берничә ел элек Санкт-Петербургта уздырылган Россия Сабан туена ишегалды өчен капка ясарга куштылар. Анда Татарстан исеменнән Азнакай районы чыгыш ясаган иде. Бер ай эшләдем мин аны. Бик матур килеп чыкты. Бәйрәмгә килүчеләр фотосессия ясап рәхәтләнделәр. Иптәшләрем, шаяртып, шул капка янында һәрберсеннән өч тәңкә акча сорап торсаң да, миллионер булып кайта идең бит, диделәр. Аннан «Дуслык» басмасы ясадым. Башкортстанның Бакалы районына бәйрәмгә алып бардым. Соңыннан: «Гади басмасына басып теләкләреңне теләсәң, бөтенесе дә кабул була», – дип сөйләнеп йөрделәр.

:: Туган җирегез турында шундый илһамланып сөйлисез...

– Әйттем бит, баш-аягым белән шунда кереп чумдым. Әле менә фольклор буенча фестиваль үткәрергә җыенып йөрибез. Матур бит безнең Азнакай. Ул таулары тагын! Диңгез өстеннән 362 метр биеклектә. Сезне өстән генә карап торабыз. Шаяртам гына инде. Җитдирәк сөйләшсәк, минем, чыннан да, туган як тарихын өйрәнергә исәбем бар. Шул җәһәттән авылда музей ачарга җыенабыз. Мин элек концертлар алып барганда, тамашачылар күңелен күреп, «миңа не везет» дип мәзәкләр сөйләп йөри идем. Әйтерсең лә, юраган юш килә. Укуымны тәмамлап, эшкә кайткан идем – клуб ябылды, партиягә керәм дип документлар әзерләп кенә бетердем, анысын да юк иттеләр. Инде лаеклы ялга чыгам дип шатланып йөргәндә генә пенсия яшен озайттылар. Шуңа күрә ул-бу була күрмәсен, хыяллар тормышка ашып, эшләп бетерергә язсын дип телим.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯБЫГУНЫҢ ДА ҖАЕ БАР

Сәламәтлек

Язга аяк бастык. Кыш дәвамында (бигрәк тә Яңа ел ялын искә төшерсәк) җыйган артык авырлыктан котылыр чак җитте, чөнки тиздән итәк-күлмәк, җиңел киемгә күчәчәкбез. Берәүнең дә зифа буй-сын урынына артык авырлыкны күрсәтәсе килмидер. Фитнес-тренер Искәндәр ШӘМСУАРОВтан язга әзерләнү, дөрес туклану турында сораштык.

:: Искәндәр, язга аяк бастык, инде кыяфәтне дә тәртипкә китерәсе килә. Кыш буе җыйган артык килограммнардан ничек котылырга? Эшне нәрсәдән башларга?

– Иң беренче чиратта табибка күренергә, анализлар тапшырырга кирәк. Шуның ярдәмендә кеше үзенең хәлен, физик мөмкинлекләрен аңлаячак. Бу, барыннан да бигрәк, сәламәтлеккә бәйле каршылыклар булмасын өчен дә кирәк. Анализлар тапшырганда кешенең теге яисә бу ризыкка аллергиясе барлыгы-юклыгы да ачыкланырга мөмкин. Бу ни өчен мөһимме? Нинди дер азык-төлеккә аллергия булганда, организмда су тотыла. Ябыгу-ябыкмау шушыңа да бәйле. Нинди ризык ашарга, кайсын юк – бу һәр кеше өчен индивидуаль хәл ителә. Артык килограммнардан котыласы килә икән, моны телевизор һәм интернеттан күнегүләр карап кына башкарып булмый. Мөмкинлеге булган кеше залда шөгыльләнсен иде. Күнегүләрне дөрес итеп эшләргә кирәк. Өй шартларында дөрес башкармаган күнегүдән зыяны күбрәк булуы ихтимал. Ябыгуның 80 проценты дөрес туклануга бәйле булса, 20 проценты физик күнегүләрдән тора.

СОЛЫ КОЙМАГЫ

Өч йомырка, он, солы лачауларын (овсяные хлопья) блендер ярдәмендә болгатабыз. Бердәй массага китерәбез. Табаны аз гына майлап, коймак рәвешендә ике яктан кыздырабыз. Коймакны табынга җиләк-җимеш, арахис пастасы белән бергә бирергә мөмкин. Калорияле дә түгел, файдалы да.

:: Ашауны ничек көйләргә? Нәрсәдән баш тартырга?

– «Мин дөрес тукланам, тик ябыга алмыйм» дигәнне еш ишетәбез. Бу очракта эндокринологка күренергә киңәш итәм. Тагын бер очрак бар әле. Еш кына: «Минем ябыгасым килә, әмма фаст-фуд, баллы, камыр ризыкларыннан баш тарта алмыйм!» – диләр. Рационнан яраткан ризыкларыгызны сызарга ашыкмагыз. Кискен үзгәреш организмга зыянга булачак. Майлы, кызган ризыкларны әкренләп чикләвек, яшелчә, җиләк-җимешләргә алмаштырыгыз. Аларда барлык кирәкле витаминнар тупланган.

Барлык кешегә дә бер төрле ябыгу төре килешми. Хәзер диеталар бик күп төрле. Интервал саклап диета тоту, аксым һәм углеводларны чиратлау кебек диеталар киң таралган. Әйтүемчә, аларны да белгечләр белән киңәшләшеп сайларга кирәк.

Мисалга бер туклану төре. Иртән бер стакан су, витаминнар эчәргә кирәк. Ябыкканда күп кенә файдалы элементлар юк була, шуңа аларны витаминнар комплексы белән тутыру зарур. Иртән 20 г чикләвек, ике күкәй (сарысы), ботка ашарга киңәш ителә. Төшке ашка дөге, карабодай, ак балык (минтай, дорадо, сибас) әзерләгез. Кызыл ит, кызыл балыкны чикләп торырга кирәк, чөнки, әйтүемчә, ябыкканда су күп тотыла. Кичтән исә күркә ите, тавык түше, диңгез ризыклары (кальмар), яшелчә ашарга мөмкин. Төп һәм мөһим шарт: кичке алтыдан да соңламаска кирәк. Әлбәттә, су эчәргә! Бу әле бер төрле меню гына.

Ябыкканда начар кәефкә игътибар бирмичә йөрү дә дөрес түгел. Бу – организмга нидер ошамый дигән сүз. Димәк, туклану рационын кабат күз уңыннан үткәрү зарур. Озакламый чәч коелу, тырнак сыну, авыз эче кибү, баш авырту күренешләре барлыкка килү ихтимал. Бу очракта да ярдәмне җиләк-җимеш, яшелчәдән табарбыз. Көнгә берничә мәртәбә яшелчә салаты ашарга кирәк. Ябыкканда еш һәм аз күләмдә ашарга киңәш ителә. Ябыкканда КБЖУ дәрәҗәсен (К – калория, Б – белок (аксым), Ж – жиры (майлар), У – углеводлар. – **Ред.**) истә тотарга кирәк. Ул балансга булса, ябыгу бик тиз барачак.

:: Су эчүнең файдасы турында да әйтик инде.

– Су күләме дигәндә, гәүдә авырлыгын 30га тапкырлап, көнe буена әнә шул күләмдә (мл. – **Ред.**) чиста су эчәргә киңәш ителә. Һәр ике сәгать саен су эчеп торсагыз, нормагыз үтәләчәк.

:: Искәндәр, тиз ябыгам дип, артыгын кыланучылар, көннәр-атналар буе ач торучылар да бар. Бу бик үк дөрес юл түгелдер инде?

– Моның уңай һәм тискәре яклары күп. Ашамыйча торып, ашказаны чирләренә юлыгырга мөмкин. Белмичә ябыкканчы, табиб-белгечләр белән киңәшләшеп эшләү кулайрак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«ВТ» белешмәсе

- Искәндәр Шәмсуаров 3,5 ел Лениногорск районындагы Ромашкино бистәсендә физик культура укытучысы булып эшләгән.
- Спортка мәхәббәтне әтисе тәрбияләгән, яшьтән үк төрле спорт ярышларына йөрткән.
- Ашарга пешерергә ярата, велосипедта йөри.
- Күпбалалы әти.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 230

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+